# Фатих Кәрим-үлемсез шагыйрь

Башкарды:Галиуллина Зилә 7Б сыйныфы укучысы

# ФАТИХ КӘРИМНЕҢ ТОРМЫШ ЮЛЫ



- Фатих Кәрим 1909 елның 9 гыйнварында Башкортстанның Бишбүләк районы Ает авылында Әхмәтвәли мулла гаиләсендә унберенче – төпчек бала булып дөньяга килә.



Җир төзелеше техникумында укыганда булачак әдип ныклап әдәби һәм иҗтимагый эшчәнлеккә тартыла. А. Алиш, Г.Минский, М. Әмир һәм башка бик күп дуслар таба.

**Рәсемнәрдә Фатих Кәрим үзенең якын дуслары белән.**



# СУГЫШ ЧОРЫ

1941 елның 30 декабрендә Ф. Кәрим армия сафларына алына.1942 елның февраленннән алып 1945 елның февраленә кадәр фронтның алгы сызыгында була.




Сугыштагы батырлыклары өчен Кызыл Йолдыз ордены, I дәрәҗә Дан ордены, медальләр белән бүләкләнә.



Фатих Кәрим сугышта кулына корал тотып та, каләм тотып та көрәшә. Аның “Кереш җыр” исемле шигырен искә төшерик:

Мин рядовой солдат булдым бу сугышта,
Тик бер нәрсә белән аерылам:
Рядовойлар төнен йоклаганда,
Мин йокламадым шатлык, кайгыдан.



Ф.Кәрим – кешелексезлекнең вәхшилекнең аяусыз дошманы. Ул, күп милләтле илебезнең барлык солдатлары белән бер сафта торып, фашизм белән бугазлаша.




Фашист илгә үлем китерә,

Фашизмның таңы, язы юк.

Яшен уты белән күккә язып үтәм:

Язы юкның яшәү хакы юк!(Бездә яздыр)


# Фатих Кәрим- үлемсез

- Фатих Кәрим - бөек Ватаныбызның тугрылыклы солдаты, үз иле, үз туган җире, туган туфрагы өчен чын күңеленнән кайгыртучы батыр сугышчы, кайнар йөрәкле шагыйрь. Фашизмга каршы авыр көрәш көннәрендә ул җырны байрак итеп күтәрде, аны батырлар данын мәңгеләштерә торган үлемсез һәйкәл, буыннардан буыннарга күчә торган халык мәхәббәте итеп күрде.
  Үләм икән, үкенечле түгел
  Бу үлемнең миңа килүе,
  Бөек җыр ул - Бөек Ватан өчен
  Сугыш кырларында үлүе,-
  дип язды ул «Ватаным өчен» шигырендә.

# Фатих Кәрим музее



# Ф.Кәрим бюсты



Игътибарыгыз өчен рәхмәт!